МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.11.2019. г.Казань № 978

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 3 декабрендә 5904 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 11 ноябрендәге 978 номерлы боерыгы белән расландылар

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 639 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 12.10.2015 №730, 19.05.2016 №278, 28.11.2016 №668, 08.06.2017 №349, 07.05.2018 №350, 18.09.2018 №858, 22.04.2019 №290, 19.08.2019 №635 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүчеләр: белем бирү оешмасы белән килешү төзи торган һәм Татарстан Республикасы территориясендә мәктәпкәчә белем бирү буенча төп белем бирү программасын гамәлгә ашыручы тиешле мәгариф оешмасына бала караштырып торган һәм караган өчен ата-ана түләвен керткән законлы вәкил (ата-ана, уллыкка алучы, опекун) (алга таба – Гариза бирүче).

1.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзенә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелде.»;

1.4.2 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пуктның алтынчы абзацында «(алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның бишенче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Мәктәпкәчә белем бирү буенча мәгариф программасын тормышка ашыручы белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация (алга таба – ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация) билгеләү | Нигезләмәнең 1 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | Нигезләмәнең 3 п. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | Нигезләмәнең 9 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша | Ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гаризаны һәм | Нигезләмәнең 9 п. |

| | | |
|---|---|---|
| торган оешмаларга мөрәҗәгать итү, зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | документларны теркәгән көннән соң ун эш көне эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Карарны бирү бер бирелә торган түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | |
| 2.5. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури булган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, аларны, шул исәптән электрон рәвештә, гариза бирүче тарафыннан алу ысуллары, аларны тапшыру тәртибе | 1. Банк яки башка кредит учреждениесендә ачылган (компенсацияне банк аша алганда) шәхси счет реквизитларын күрсәтеп, компенсация билгеләү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.<br>2. Компенсация түләнә торган баланың туу турында таныклык күчермәсе – бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда.<br>3. Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә гариза бирүченең гаилә составында исәпкә алынган, компенсация билгеләнә торган бала туганчыга кадәр туган баланың (балаларның) тууы (уллыкка алынуы) турында таныклыкларның күчермәсе, – баланың (балаларның) тууы турындагы акт Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән очракларда. | Нигезләмәнең 8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | 4. Белем бирү оешмасыннан көндезге уку формасы буенча 18 яшьтән алып 23 яшькә кадәрге балаларны укыту турында белешмә.<br>5. 2015 елның 30 сентябренә кадәр мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән килешү төзегән затлар өчен – баланы тиешле белем бирү оешмасына урнаштыру турында килешү күчермәсе.<br>6. Баланың табель саны турындагы белешмәләр булган документ (документ күчермәсе) (мәктәпкәчә белем бирү оешмасында баланы караштырган һәм караган өчен түләү турында квитанция күчермәсе), – мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән 2015 елның 30 сентябренә кадәр килешү төзегән затлар өчен.<br>7. Гариза бирүченең 18-23 яшендәге, көндезге формада белем бирү оешмаларында белем ала торган гаилә әгъзаларыннан (ирекле формада) документ (документлар), түбәндәгеләрне раслый торган:<br>аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү ризалыгы булуны;<br>шәхси мәгълүматларны үзәк бүлегенә тапшырганда гариза бирүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.<br>Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Гариза бирүчеләрнең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә гариза бирүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар гариза бирүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан таныклана.<br>Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхес таныклаучы документ күчермәсеннән тыш) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә белгеч шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза белән документлар шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Зеленодольск шәһәрендә яшәүчеләр өстәмә рәвештә гаризаны Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша да җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан | |

| | | |
|---|---|---|
| | Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырылган. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны, шул исәптән электрон формадагыларын да, алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар шулар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:<br>бала (балалар) туу акты Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән очракта – балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында белешмәләр (вәкаләтле органнарда);<br>балага опека билгеләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>баланы гаиләгә тәрбиягә тапшыру турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>дәүләт хезмәте алучының ата-аналык хокукыннан мәхрүм ителүе яисә ата-аналык хокукында чикләнүе турында белешмәләр (җирле үзидарә органнарында);<br>мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән зат турында белешмәләр, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен (Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгында);<br>мәгариф оешмасында баланы караштырган һәм тәрбияләгән өчен түләү квитанциясендә күрсәтелгән табель номеры турында белешмәләр, – 2015 елның 30 сентябреннән соң мәктәпкәчә белем бирү оешмасы белән шартнамә төзегән затлар өчен (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);<br>Гариза бирүче Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша | Нигезләмәнең 8.1 пункты 20 номерлы тәртипнең 6 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте Инфоматлары аша мөрәҗәгать иткән очракта, ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша өстәмә рәвештә гариза бирүченең паспортының чын булуын раслау турында белешмәләр алына (Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгында).<br>Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтең күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы.<br>2. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>3. Үзәк бүлегенә 63-ФЗ һәм 210-ФЗ номерлы федераль законнардагы таләпләргә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар рәвешендә гариза һәм документларның (документларның күчермәләренең) тапшырылуы.<br>4. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү | |

| | | |
|---|---|---|
| | очрагында документларның төп нөсхәләренең күрсәтелмәве.<br>5. Гариза бирүченең документларның Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган күчермәләрен почта аша җибәрүе. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:<br>әлеге Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>тулы булмаган һәм (яисә) ялган (төгәл булмаган) мәгълүматлы гариза һәм (яисә) документлар тапшырылуы | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 п. |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәттән файдалану турындагы гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла. | |

| | | |
|---|---|---|
| тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;<br>инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр | 880 номерлы Тәртипнең 2.4. пункты, Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы |

| | | |
|---|---|---|
| итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә | алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>Үзәкнең мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>гариза бирүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталындагы шәхси кабинет аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары сақлану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан шушы Регламентны бозып кылынган | указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау; | прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булуы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәргәндә бәйләнешкә керү таләп ителми;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша яисә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматларыннан җибәргән очракта турыдан-туры бергәләп эш итү таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә эш итүенең дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация | Нигезләмәнең 23 п., Россия Федерациясе Президентының |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша җибәрелергә мөмкин, түбәндәгеләрдән тыш:<br>гариза гариза бирүче тарафыннан билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләт алган затлар тарафыннан тапшырылганда;<br>гаиләсендә туу турындагы актлары Татарстан Республикасыннан читтә теркәлгән балалар булган яки белем алуның көндезге формасында белем ала торган 18-23 яшьлек балалары булган гариза бирүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта.<br>Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы яки Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза биргәндә дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе электрон формада бирелә | 601 номерлы указының 1 п. |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

мәгълүматлар алу, ведомствоара мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

ата-ана түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен гражданин шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гариза бирүчегә тапшыру яки дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен почта буенча җибәрү.»;

3.1.2 пунктчаны гамәлдән чыккан дип танырга;

3.3.1 пунктчаның җиденче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.5.1 пунктчаның өченче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

«(гариза бирүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның мәнфәгатьләрен яклау вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)» сүзләрен «(ышанычлы зат яки законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклый торган затның вәкаләтләрен раслый торган документ реквизитлары)»;

«Гариза бирүченең имзасы» сүзләрен «Гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклаучы затның имзасы» сүзләренә алмаштырырга;

«Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләрен «Гариза бирүченең яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүченең мәнфәгатьләрен яклаучы затның фамилиясе, исеме, атасының исеме» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 4 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Мәктәпкәчә белем бирү программасын тормышка ашыручы гомуми белем бирү оешмаларында баланы караштырып торган һәм караган өчен ата-аналар түләвенең бер өлешенә компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 14 апрелендәге 231 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 № 317, 26.06.2017 № 416, 07.05.2018 № 348, 15.05.2018 № 365, 18.09.2018 № 858, 24.06.2019 № 494 боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Гариза бирүчеләр:

хроник бөер җитешсезлеге белән интегүче, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының ике тапкыр күләменнән түбән булган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалана торган затлар;

җан башына исәпләгәндә уртача айлык кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумының икеләтелгән күләменнән азрак булган, онкология чирләреннән интегүче затлар.»;

1.3 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

1.4 пунктта һәм алга таба Регламент тексты буенча «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләрен тиешле килеш кушымчаларында һәм саннарда кулланып, тиешле килешләрдә һәм саннарда «гариза бирүче» сүзләренә алмаштырырга;

1.4.1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба – Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелде.»;

1.4.2 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Үзәк бүлекләрендә гариза бирүчеләр белән эшләү бүлмәләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Мәгълүмат стендларында Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;»;

2 пунктчаның дүртенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга;

1.5 пуктның алтынчы абзацында «(алга таба – РФ Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләрен «(алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указы)» сүзләренә алмаштырырга;

1.6 пунктның дүртенче абзацында икенче җөмләне төшереп калдырырга;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор | 743 номерлы тәртипнең 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү | |
| 2.2. Башкарма хакимият органы (учреждение) атамасы | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 743 номерлы тәртип буенча 11 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | 743 номерлы тәртипнең 16 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү срогы, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган | Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап ун көн эчендә кабул ителә.<br>Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Карарны бирү бер бирелә торган түләүне билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар кабул ителгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла | 743 номерлы тәртипнең 16 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| документларны бирү (җибәрү) срогы | | |
| 2.5. Закон яки башка төрле норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен, кирәкле һәм зарури булып торган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. Банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган хосусый счет реквизитларын күрсәтеп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасындагы форма буенча компенсация билгеләү турында гариза.<br>2. Дәвалану урынына килү һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын раслаучы документлар (булган очракта), түбәндәге транспорт төрләрендә:<br>тимер юл транспорты (барлык категориядәге поездлар һәм вагоннар, фирмалы поездлардан һәм югары уңайлыклы вагоннардан тыш);<br>су транспорты (III категорияле);<br>шәһәрара һәм шәһәр яны билгеләнешендәге (уртак файдаланудагы) автомобиль транспорты;<br>тимер юл булмаганда авиация транспорты (эконом класс).<br>3. Гариза биргән айдан алда килүче 3 айда гаиләнең һәр әгъзасы тарафыннан акчалата һәм натураль формада алынган керемнәр турында документлар, шул исәптән:<br>а) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Уртача хезмәт хакын исәпләп чыгару тәртибе үзенчәлекләре турында» 2007 елның 24 декабрендәге 922 номерлы карары нигезендә уртача хезмәт хакын исәпләгәндә исәпкә алына торган, хезмәткә түләү системасында каралган барча түләүләр турында»;<br>б) хезмәт законнарында каралган очракларда саклана торган уртача хезмәт хакы турында;<br>в) дәүләти яисә иҗтимагый бурычларны үтәү вакытына дәүләт | 743 номерлы тәртипнең 7, 11, 13 пунктлары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 512 номерлы карары |

| | | |
|---|---|---|
| | органы яисә иҗтимагый берләшмә тарафыннан түләнә торган компенсация турында;<br>г) эштән куылганда түләнә торган ял пособиесе, отставкага киткәндә компенсация, оешма ликвидацияләнүгә, хезмәткәрләр санын яисә штатын кыскартуга бәйле рәвештә эштән куылганда хезмәткә урнашу чорына саклана торган хезмәт хакы турында;<br>д) барлык дәрәҗә бюджетлардан, дәүләтнең бюджетка карамаган фондларыннан һәм башка чыганаклардан социаль түләүләр, андыйларга түбәндәгеләр керә:<br>пенсияләр, компенсация түләүләре (эшләми торган хезмәткә сәләтле, хезмәткә сәләтсез булган гражданнарны караучы затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм ай саен түләнә торган пенсионерларның матди тәэминаты (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан түләнә торган түләүләрдән гайре);<br>отставкага киткән судьяларны ай саен гомер буе тәэмин итү;<br>һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы аспирантларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучыюгары белем бирүче мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар докторантларына түләнә торган стипендияләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отпускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация түләүләре; | |

| | | |
|---|---|---|
| | контракт буенча хәрби хезмәт үтүче хәрби хезмәткәрләрнең билгеләнгән тәртиптә эшсез буларак танылган хатыннарына ирләре белән яшәгән җирлекләрдә эшләмәскә мәҗбүр булган яисә белгечлеге буенча эшкә урнашу мөмкинлеге булмауга бәйле эшкә урнаша алмаган чорда, шулай ук хәрби хезмәткәрләрнең хатыннары балаларының, әгәр сәламәтлек саклау учреждениесенең бәяләмәсе буенча аларның балалары 18 яшенә җиткәнче читләрнең каравына мохтаҗ булса, ирнең хәрби хезмәт урыны буенча яшәү шартларына бәйле рәвештә сәламәтлеге торышы буенча эшләмәскә мәҗбүр булган чорда ай саен түләнә торган пособие;<br>Россия Федерациясе эчке эшләр органнарының һәм аларны эш белән тәэмин итү мөмкинлеге булмаган читләштерелгән гарнизоннарда һәм җирлекләрдә җинаять-үтәтү системасы учреждениеләренең рядовой һәм җитәкчелек итүче составындагы затларның эшләмәүче хатыннарына ай саен түләнә торган компенсация түләүләре;<br>җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча ай саен түләнә торган иминият түләүләре;<br>әлеге пунктчада күрсәтелгән барлык төр социаль түләүләргә өстәмә һәм кушып түләүләр (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән бүтән социаль түләүләр | |

| | | |
|---|---|---|
| | (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>е) хезмәт шартнамәсе шартларында хезмәт мөнәсәбәтләрендә торучы һәм 3 яшенә җиткәнче бала карау ялында булган гражданнарга айлык компенсация түләүләре (социаль яклау органнарыннан түләнүче түләүләрдән тыш);<br>ж) милекчелек хокукында гаиләнеке (андагы аерым әгъзаларныкы) яисә ялгыз яшәүче гражданинныкы булган мөлкәттән алынган керемнәр, андыйларга түбәндәгеләр керә:<br>күчемсез мөлкәтне (җир кишәрлекләрен, йортларны, фатирларны, дачаларны, гараждарны), транспорт һәм бүтән механика чараларын, продуктларны эшкәртү һәм саклау чараларын сатудан һәм арендага (наемга) бирүдән алынган керемнәр;<br>шәхси ярдәмче хуҗалык уңышын һәм продукциясен (күп еллык утыртмалар, яшелчәчелек продукциясе, продукция һәм демонстрация хайваннары, кошлар, кыйммәтле мехлы җәнлекләр, бал кортлары, балыклар) сатудан алынган керемнәр;<br>з) гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданинның башка керемнәре турында, аларга түбәндәгеләр керә:<br>хәрби хезмәткәрләрнең, Россия Федерациясе эчке эшләр органнары, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе таможня органнары һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнарның хезмәткәрләренең акчалата тәэминаты, шулай ук даими | |

| | | |
|---|---|---|
| | холыкка ия булган өстәмә түләүләр һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгәнчә азык-төлек тәэминаты;<br>хәрби хезмәттән, Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан, җинаять-үтәтү системасы учреждениеләреннән һәм органнарыннан, Россия Федерациясе таможня органнарыннан һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә аларда хокук саклау эшчәнлегенә бәйле булган федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнардан эштән киткәндә бер мәртәбә бирелә торган пособие;<br>Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә төзелә торган шартнамәләр буенча эшләргә түләү;<br>эш бирүчеләр тарафыннан үзләренең, шул исәптән инвалидлык яисә яше җитүгә бәйле рәвештә пенсиягә чыгу сәбәпле элеккеге, эштән киткән хезмәткәрләренә матди ярдәм;<br>Россия Федерациясенең авторлык хокукы һәм катнаш хокуклар турында законнары нигезендә алына торган авторлык бүләкләүләре, шул исәптән мирас итеп алуның авторлык шартнамәләре буенча;<br>эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнүләрдән алынган керемнәр, крестьянлык (фермер) хуҗалыгы, шул исәптән юридик зат төземичә хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә алынган керемнәр;<br>акцияләр буенча керемнәр һәм оешма мөлкәте белән идарә итүдә катнашудан алынган башка керемнәр;<br>гаилә әгъзалары тарафыннан алына торган алиментлар;<br>банк кертемнәре буенча процентлар;<br>мирас итеп алына һәм бүләк ителә торган акча чаралары; | |

| | | |
|---|---|---|
| | Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән ташламалардан һәм социаль гарантияләрдән гаилә әгъзалары алган акчалата эквивалентлар.<br>4. Гариза бирүченең гаилә әгъзаларыннан яисә аларның законлы вәкилләреннән (ялгыз яшәүче гражданиннан кала) ирекле формада документ (документлар), түбәндәгеләрне раслаучы:<br>аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү ризалыгы булуны;<br>шәхси мәгълүматларны органга яисә оешмага тапшырганда мөрәҗәгать итүченең алар исеменнән эш кылуга вәкаләтле булуын.<br>5. Ышанычлы затлар өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә.<br>Әлеге Регламентның 1.2 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән гражданнар өстәмә рәвештә медицина оешмасыннан гражданинның амбулатор гемодиализ процедураларын узу датасы турында белешмәләрне үз эченә алган белешмәне дә тапшыра. Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә. Документларның күчермәләре, әгәр алар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә күрсәтелә һәм Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан таныклана.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына. | |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гаризаны шулай ук Үзәк бүлегендә шәхсән кабул иткәндә электрон рәвештә тутырырга мөмкин, аңа мөрәҗәгать итүче, электрон рәвештә укыла торган имзадан файдаланып, кул куя.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин. | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүченең аларны, шул исәптән | Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:<br>гариза бирүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);<br>хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре (түләүләрнең булмавы) һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында (халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан);<br>түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны тәрбия кылучы, эшкә | 743 номерлы тәртипнең 12 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| электрон формадагыларын да, алу ысуллары, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар шулар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | сәләтле эшләүмәүче затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионарларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырылучы материаль тәэмин итү буенча түләүләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);<br>физик затлар тарафыннан алынган керемнәр турында (Федераль салым хезмәтендә) (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);<br>Россия ЭЭМ тарафыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Эчке эшләр министрлыгында);<br>Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында (Россия Оборона министрлыгында);<br>социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан түләнә торган йөклелек һәм бала тудыру буенча пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие (Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органыннан);<br>йөклелекнең иртәнге срокларында медицина учреждениеләрендә исәпкә баскан хатын-кызларга социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында); | |

| | | |
|---|---|---|
| | баланы караган өчен социаль яклау органнары яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнары тарафыннан ай саен түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында яки Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органнарында);<br>социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында (социаль яклау органнарында);<br>әлеге пунктчада күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында белешмәләр (социаль яклау органнарында);<br>житештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса (Россия | |

| | | |
|---|---|---|
| | Федерациясе Социаль иминиятлəштерү фонды территориаль органнарында);<br>гражданинның дəвалануны узу чоры турында (махсус онкология ярдəмен күрсəтə торган Татарстан Республикасы медицина оешмасыннан).<br>Гариза бирүче югарыда аталган белешмəлəрне раслый торган документларны үз ихтыяры белəн дə тапшырырга хокуклы.<br>Аталган документлар гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вəкалəтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исəптəн, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һəм əлеге Регламентның 2.5 пунктында билгелəнгəн документларны тапшыру өчен əлеге Регламентта каралган тəртиптə тапшырылырга мөмкин.<br>Гариза бирүченең югарыда күрсəтелгəн документларны тапшырмавы гариза бирүчегə дəүлəт хезмəтен күрсəтүдəн баш тарту өчен нигез булып тормый.<br>Үзəк бүлеге гариза бирүчедəн түбəндəгелəрне талəп итəргə хокуклы түгел:<br>дəүлəт хезмəте күрсəтүгə бəйле рəвештə барлыкка килə торган мөнəсəбəтлəрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамəлгə ашыру күздə тотылмаган документларны һəм мəгълүматны тапшыруны яки гамəллəр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендə каралган документлардан тыш, шул исəптəн гариза бирүче тарафыннан дəүлəт хезмəтен күрсəткəн өчен түлəү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый | |

| | | |
|---|---|---|
| | актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Гариза бирүченең яшәгән урыны буенча мөрәҗәгать итмәве.<br>2. Әгәр күчермәләре законда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, шәхсән мөрәҗәгать итү очрагында гариза бирүче документларының төп нөсхәләре күрсәтелмәү.<br>3. Документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булуы. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту нигезләре: | 743 номерлы тәртипнең 17 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләренең тулы исемлеге | компенсация алу өчен мөрәҗәгать итүченең төгәл булмаган белешмәләрне һәм документларны тапшыру;<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы | |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу нигезләре | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы Указының 1 п. |
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәттән файдалану турындагы гаризасын, шул исәптән электрон рәвештә, теркәү чоры | Гариза һәм документлар кергән көннән бер көн эчендә.<br>Гариза белән кирәкле барлык документлар электрон документлар рәвешендә ял көннәрендә яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эш көне булып саналмаган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга киртәләрсез үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә. | |

| | | |
|---|---|---|
| урнаштырылган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр. Шул исәптән инвалидларны социаль яклау турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә әлеге объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә дә. | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфатлы булу күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>бүлек биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашуы;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 пункты, Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтеннән файдалану турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру юлы белән, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану (шул исәптән тулы күләмдә) мөмкинлеге яки файдалана алмау; | Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу мөмкинлеге;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.<br>Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша, | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча гариза тапшыруны кертеп, дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы рәсми мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза һәм гариза бирүченең гаилә әгъзаларының яки аларның законлы вәкилләренең үзләренең шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын раслый торган документ гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш | 210-ФЗ номерлы федераль закон, 63-ФЗ номерлы федераль закон |

3 бүлектә:

бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре»;

3.1.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, шул исәптән гариза төзү өлешендә;

компенсация билгеләү буенча документлар җыелмасын теркәп, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

мәгълүматлар алу, ведомствоара үтенечләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.»;

3.1.2 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

3.3.2 пунктчаның беренче абзацында «2.8» саннарын «2.7» саннарына алмаштырырга;

3.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында;

эшсезлек буенча барлык төр пособие түләүләре һәм эшсезләргә башка төрле түләүләр турында, халыкны эш белән тәэмин итү буенча дәүләт хезмәте органнарыннан;

түбәндәгеләрне алу һәм аларның күләмнәре турында: пенсияләр, компенсация түләүләре (эшкә сәләтсез гражданнарны караучы, эшкә сәләтле эшләми торган затларга түләнә торган компенсация түләүләреннән тыш) һәм пенсионерларны ай саен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фонды тарафыннан гамәлгә ашырылучы матди тәэмин итү буенча түләүләр Россия Федерациясе Пенсия фондыннан;

социаль яклау органнары тарафыннан йөклелек һәм бала тудыру буенча түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр, социаль яклау органнарыннан;

йөклелекнең башлангыч срокларында медицина учреждениеләренә исәпкә куелган хатын-кызларга социаль яклау органнары тарафыннан бер мәртәбә түләнә торган пособие күләмнәре турында белешмәләр, социаль яклау органнарыннан;

социаль яклау органнары тарафыннан бала караган өчен түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында белешмәләр, социаль яклау органнарыннан;

вакытлыча эшкә сәләтсез булуга бәйле пособие – Социаль иминиятләштерү фондының территориаль органыннан;

социаль яклау органнары тарафыннан балага түләнә торган айлык пособие күләмнәре турында – социаль яклау органнарыннан;

әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән, социаль яклау органнары түли торган барлык социаль түләү төрләренә өстәмә һәм кушып түләү күләмнәре турында, – социаль яклау органнарыннан;

Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары, җирле үзидарә органнары, оешмалар тарафыннан билгеләнгән, социаль яклау органнары тарафыннан түләнә торган бүтән социаль түләүләрнең күләмнәре турында – социаль яклау органнарыннан;

физик затлар тарафыннан алынган керемнәр турында, Федераль салым хезмәтеннән (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: алынган белешмәләр.»;

3.4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында мөрәҗәгатьләр җибәрә:

махсус онкология ярдәмен күрсәтә торган Татарстан Республикасы медицина оешмасыннан гражданинның дәвалануны узу чоры турында (онкологик чирләрдән интегүче затларга компенсация билгеләнгәндә);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фондында;

вәкаләтле оешмалардан гариза бирүченең гаилә составы турында;

Россия Оборона министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында – Россия Оборона министрлыгына;

җитештерүдә бәхетсезлек очракларыннан һәм һөнәри авырулардан мәҗбүри социаль иминиятләштерү буенча иминиятләштерелгән гражданнарга түләнә торган айлык иминият түләүләре турында, әгәр медик-социаль экспертиза учреждениесе бәяләмәсе буенча иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып аның профессиональ эшкә сәләтен югалтуы торса, яисә аларны алу хокукына ия булган затларга, – әгәр иминият очрагы барлыкка килүнең нәтиҗәсе булып иминиятләштерелгән затның вафаты торса, – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

вакытлыча эшкә сәләтле булмауга бәйле пособие, йөклелек һәм бала тудыруга бәйле пособие, шулай ук медицина учреждениеләрендә йөклелекнең башлангыч срокларында исәпкә алынган хатын-кызларга бер бирелә торган пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органына;

бала караган өчен айлык пособие күләмнәре турында – Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды территориаль органнарына;

Россия Эчке эшләр министрлыгыннан түләнә торган пенсия күләме турында, – Россия Эчке эшләр министрлыгына;

физик затлар тарафыннан алынган керемнәр турында, Федераль салым хезмәтенә (әлеге абзац таләбе 2020 елның 1 июленнән гамәлдә);

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны килгән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгать.»;

3.5.1 пунктчаның икенче абзацында «2.9» саннарын «2.8» саннарына алмаштырырга;

3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Техник хата төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 5 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлектә:

4.2 пунктның беренче абзацында «(алга таба - Идарә (бүлек))» сүзләрен төшереп калдырырга;

4.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.»;

5 бүлек аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәтен күрсәтә торган органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.1 пунктта дүртенче абзацны көчен югалткан дип танырга;

5.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.8. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләренең составы ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение хезмәткәре булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына

транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә

______________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____
«___» ____________ 20___ ел.

Мин,

__________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта) тулысынча)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафын нан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

түбәндәге адрес буенча яшим:

__________________________________________________________________________
(индексын күрсәтеп мөрәҗәгать итүченең почта адресы, телефон номеры, электрон почта адресы)
түбәндәгеләргә нигезләнеп эш итәм:

__________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)
Гариза бирүченең хосусый иминият номеры
Билгеләвегезне сорыйм ___________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)
түбәндәге адрес буенча яши торган:

__________________________________________________________________________
(почта индексы, мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча теркәлү адресы)

__________________________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең шәхесен таныклый торган документ реквизитлары)

| № | Социаль ярдәм чаралары | Кирәклесен билгеләргә |
|---|---|---|
| 1 | бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ | |

| | | |
|---|---|---|
| | ысулы белән дәва алучы затларга амбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация | |
| 2 | онкологик чирләрдән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасының махсус онкология ярдәмен күрсәтә торган медицина оешмаларына дәвалану урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире әйләнеп кайту чыгымнарына компенсация | |

Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| № | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| 1 | | |
| 2 | | |
| 3 | | |
| 4 | | |

Гариза бирүченең гаилә составы:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме (туган көне, ае, елы) | Туганлык мөнәсәбәтләре | Паспорт (бала туу турында таныклык) реквизитлары |
|---|---|---|---|
| 1 | | | |
| 2 | | | |
| 3 | | | |
| 4 | | | |

Билгеләнгән компенсацияне түбәндәгечә түләү турында үтенәм:
счетка күчерү юлы белән ________________________________________________
(билгеләнгән тәртиптә гариза бирүче яки аның законлы вәкиле тарафыннан ачылган счет реквизитлары күрсәтелә)
почта бүлеге аша ________________________________________________
(гариза бирүченең яисә аның законлы вәкиленең почта реквизитлары күрсәтелә)
Тапшырылган белешмәләрнең дөрес булуы, аларны үз эченә алган документларның чын булуы һәм социаль ярдәм чараларын түләүгә йогынты ясый торган шартлар

турында үз вакытында хәбәр итү җаваплылыгы турында белəм

________________________________________

(гариза бирүченең яисә гариза бирүче мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә белдерүче затның имзасы)

Мәгълүмат, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) да, алуга риза:

почта адресы буенча язма формада _________________________

әлеге телефонга смс-хәбәр итеп _______________________________________

(телефон номеры)

электрон документ формасында

әлеге электрон почта адресына _____________________________________

(электрон почта адресы)

Гариза бирүче яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче мәнфәгатьләрен белдерә торган затлар:

________________________________________ ____________» __ » _________ 20_ ел.

(гариза бирүченең яисә гариза бирүче мәнфәгатьләрен билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә белдерүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

__________ _______________________________

(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

Өзү линиясе

Язу-белдерү

Гариза бирүченең теркәлү номеры __________________

Документлар саны ____ данә, __ биттә

Документларны кабул итте__________ __________ ________________________ _______

(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Регламентка 4 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга;

Регламентка (белешмәлек) кушымтаны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Бөеренең хроник рәвештә җитәрлек дәрәҗәдә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм

онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Бөеренең хроник рәвештә житәрлек дәрәждә эшләмәвеннән интегүче, амбулатор гемодиализ ысулы белән дәва алучы затларга авмбулатор гемодиализ үтү урынына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплау буенча компенсация билгеләү һәм онкология чирләреннән интегүче затларга Татарстан Республикасы дәүләт сәламәтлек саклау системасындагы махсуслаштырылган онкология ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларына транспортта бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын каплауга компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

1. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru». |